ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы депутат берләшмәләреннән Татарстан Республикасы Рәисенә җибәрелә торган мәсьәләләр исемлеге хакында (Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында еллык хисапны тәкъдим итүгә бәйле рәвештә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы куйган мәсьәләләр буенча, еллык хисапны тәкъдим итү хакындагы $190^2$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы депутат берләшмәләреннән мәсьәләләр исемлеген Татарстан Республикасы Рәисенә җибәрергә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2026 елның 13 феврале
№ 142-VII ДСП

2026 елның 13 февралендәге
142-VII ДСП номерлы
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумы
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы депутат берләшмәләреннән Татарстан Республикасы Рәисенә җибәрелә торган мәсьәләләр исемлеге**

*Икътисад, бюджет*

1. Республика икътисадын диверсификацияләү һәм нефть-газ секторыннан бәйлелекне киметү өчен 2025 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан күрелгән чаралар турында.

2. Югары технологияле тармакларга инвестицияләр җәлеп итү планын гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында.

3. 2025 елга Татарстан Республикасында импортны алмаштыру программасын гамәлгә ашыру йомгаклары турында.

4. Татарстан Республикасы сәнәгать предприятиеләрен цифрлы трансформацияләү программасын үтәү барышы турында. Республика агросәнәгать комплексын цифрлы трансформацияләү темпларын үстерү өчен, шул исәптән цифрлы компетенцияләргә ия булган югары квалификацияле кадрлар әзерләү өлешендә, күрелә торган чаралар турында.

5. Салым законнарындагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә Татарстан Республикасында кече һәм урта бизнеска күрсәтелә торган ярдәм чаралары турында.

6. Татарстан Республикасында «Салым салуның автоматлаштырылган гадиләштерелгән системасы» һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимнарын билгеләү экспериментын гамәлгә ашыру барышы турында.

7. Татарстан Республикасында халык сәнгать һөнәрләренә ярдәм итү һәм аларны үстерүгә кызыксындыру чаралары турында.

8. Татарстан Республикасы сәнәгать предприятиеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү чаралары турында.

9. Һөнәр төрләре буенча бердәм республика цифрлы вакансияләр базасын булдыру мөмкинлеге турында.

*Тормыш инфраструктурасы*

10. Татарстан Республикасында җәмәгать урыннарын, шул исәптән яңа гамәлгә кертелгәннәрен, тоту өлешендә үткәрелә торган эш турында.

11. Татарстан Республикасында торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуы (күзәтчелеге) турында.

12. Татарстан Республикасында коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләүнең региональ программасын финанслауны арттыру буенча планлаштырыла торган чаралар турында.

13. Халыкка транспорт хезмәте күрсәтү сыйфатын яхшырту буенча, шул исәптән шәһәрара автобусларда йөртүләрне оештыру өлешендә, планлаштырыла торган чаралар турында.

14. Җәмәгать транспортын йөртүчеләр кытлыгы проблемасын хәл итү өчен планлаштырыла торган чаралар турында.

*Социаль сәясәт*

15. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына 2025 елда Татарстан Республикасында күрсәтелә торган дәүләт ярдәме чаралары турында.

16. Татарстан Республикасы предприятиеләрендә инвалидлыгы булган махсус хәрби операция ветераннары өчен махсус эш урыннары булдыру буенча үткәрелә торган эш турында.

17. Яшь галимнәрне фәндә һәм фәнни сыйдырышлы Татарстан предприятиеләрендә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруга өстәмә мотивацияләүне формалаштыру максатларында аларга бирелә һәм планлаштырыла торган дәүләт ярдәме чаралары турында.

18. Яраланган махсус хәрби операциядә катнашучыларга матди ярдәм буенча планлаштырыла торган чаралар турында.

19. Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итү турында, чиратлылык, көтү дәвамлылыгы, финанслауның җитәрлек булуы мәсьәләләрен дә кертеп.

20. Опекуннарга (попечительләргә) җәмәгать транспортында, попечительлектә булган баладан башка йөргән очракта, түләүсез йөрү хокукын бирү зарурлыгы турында.

21. Татарстан Республикасында алдынгы спортчыларны беркетүне тәэмин итү максатларында аларга стипендияләр һәм кызыксындыру түләүләре күләмнәрен арттыру зарурлыгы турында.

*Сәламәтлек саклау*

22. Сәламәтлек саклау өлкәсендә кадрлар кытлыгын бетерү буенча күрелә һәм планлаштырыла торган чаралар турында.

23. Онкология һәм онкогематология авырулары булган гражданнарга амбулатория-поликлиника һәм стационар медицина ярдәме күрсәтү максатларында сәламәтлек саклау системасы инфраструктурасын киңәйтү перспективалары турында.

24. Чаллы шәһәрендә «Ишетүне реабилитацияләү үзәге» дәүләт бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе бинасына капиталь ремонт үткәрү зарурлыгы турында.

25. Авыл халкын дарулар белән тәэмин итүне оештыру турында.

*Мәгариф, мәдәният*

26. Татарстан укучыларының «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия балалар һәм яшьләр иҗтимагый-дәүләти хәрәкәтенә җәлеп ителүе турында.

27. Эшче кадрлар кытлыгы проблемасын хәл итү ысулларының берсе буларак укыту-җитештерү комбинатлары (УПК) системасын торгызу мөмкинлеге турында.

28. Мәдәният учреждениеләреннән: китапханәләрдән һәм музейлардан, мәдәният йортлары биналарыннан нәтиҗәле файдалану турында.

29. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына һәм өстәмә белем бирү учреждениеләренә капиталь һәм агымдагы ремонт үткәрү турында.

30. Гражданнарга яшүсмерләр клублары һәм яшьләр үзәкләре эшчәнлеге, аларда күрсәтелә торган хезмәтләрнең төрләре, аларны күрсәтү тәртибе һәм шартлары турында мәгълүмат бирү эшен (шул исәптән балалар һәм яшүсмерләр белем ала торган мәгариф оешмалары аша) оештыру зарурлыгы турында.

31. Татарстан Республикасында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» бөтенроссия физкультура-спорт комплексын (ГТО) үстерүгә, шул исәптән матди-техник базаны ныгыту һәм хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарын исәпкә алып, финанслауны арттыру зарурлыгы турында.

*Җәмәгать иминлеге*

32. Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча үткәрелә торган эш турында.

33. Гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда, халыкны саклауга, шулай ук Татарстан Республикасы халкына үзәкләштерелгән хәбәр итүнең региональ автоматлаштырылган системасын камилләштерүгә юнәлдерелгән чаралар турында.

34. Гражданнар күпләп була торган урыннарда һәм күпфатирлы йортларда, шул исәптән газ кертелгән йортларда, җәмәгать иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасында күрелә торган чаралар турында.

35. Татарстан Республикасында миграция сәясәте өлкәсендә, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының хокукларын яклау өлешендә, күрелә торган чаралар турында.

36. Татарстан Республикасында мәгариф оешмаларында балаларның иминлеген тәэмин итү һәм балигъ булмаганнар арасында хокук бозулар санын киметү буенча күрелә торган чаралар турында.

37. Татарстан Республикасында юл-транспорт һәлакәтләре һәм юлларда һәлак булучылар санын киметү буенча күрелә торган чаралар турында.

38. Татарстан Республикасында, аерым алганда, Казан шәһәрендә, гражданнарны, шулай ук аларның берләшмәләрен җәмәгать тәртибен саклауда катнашуга җәлеп итү буенча күрелә торган чаралар турында.

*Авыл хуҗалыгы, экология*

39. Татарстан Республикасында органик игенчелекне үстерү турында.

40. Үсемлекчелек һәм терлекчелек чималын тулысынча эшкәртү буенча җитештерүне гамәлгә кертү перспективалары турында.

41. Татарстан Республикасында авылда хуҗалык итүнең кече рәвешләрен үстерү турында.

42. Татарстан Республикасында балык хуҗалыгы тармагы торышы һәм аны үстерү перспективалары турында.

43. Татарстан Республикасында экология, биология һәм ветеринария иминлеге дәрәҗәсен арттыру өчен күрелә торган чаралар турында.

44. Татарстан Республикасы елгаларының һәм сулыкларының экологик торышын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар турында.

45. Татарстан Республикасында каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә эшләр торышы турында.

*Җирле үзидарә мәсьәләләре*

46. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүдә инициатив проектларны гамәлгә ашыру перспективалары турында.

47. Җирле үзидарә органнарына беркетелә торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү нормативларын исәпләү методикасын әзерләү эше турында.